**Туфан Миңнуллин исемендәге**
**укытучыларның һәм укучыларның**
**VII республика конференциясен үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Әлеге нигезләмә халык язучысы, күренекле драматург, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге һәм ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференциясен (алга таба – Конференция) үткәрү тәртибен билгели.

## II. Конференциянең максат һәм бурычлары

Конференция татар әдәбиятын, мәдәниятен, сәнгатен һәм Туфан Габдулла улы Миңнуллинның иҗади мирасын, киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру максатыннан үткәрелә.

Конференциянең бурычлары:

- татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру;
- яшь буында толерантлык, патриотизм хисләре тәрбияләү һәм үстерү;
- Туфан Миңнуллин әсәрләрен киңрәк өйрәнү һәм алар аша яшь буында милли үзаң тәрбияләү;
- сәләтле балаларның иҗади эшләренә бәя бирү һәм сәләтләрен үстерү.

## III. Конференцияне оештыручылар

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты;
- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты;
- Казан (Идел буе) федераль университеты;
- **Казан муниципаль берәмлеге шәһәр мәгариф идарәсе;**
- **Казан шәһәре Мәскәү районының «Ф.Г.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе;**
- Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры;
- Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры;
- Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты;
- Татарстан Республикасы Язучылар берлеге.

## IV. Конференцияне оештыру һәм үткәрү тәртибе

4.1. Конференциягә **татар телендә** җибәрелгән фәнни-гамәли һәм иҗади эшләргә Татарстан Республикасының танылган сәнгать әһелләреннән, фән һәм җәмәгать эшлеклеләреннән торган жюри бәя бирә.

4.2. Конференциядә катнашу бушлай. Конференциягә җибәрелгән эшләр

авторларга кире кайтарылмый, әмма автор рөхсәте белән республика мәгълүмат чараларында кулланылырга мөмкин.

4.3. Конференциядә катнашу тәртибе:

Конференциядә Нигезләмә шартлары буенча билгеләнгән вакытка кадәр гариза (Кушымта 1 яки Кушымта 2) белән фәнни-гамәли һәм иҗади эшен җибәргән, Татарстан Республикасы урта һәм өстәмә белем бирү оешмаларында белем алучы 5-11 сыйныф укучылары, шулай ук мәктәп укытучылары һәм китапханәчеләре (Кушымта 3) катнаша ала.

4.4. Укучыларның фәнни-гамәли һәм иҗади эшләре һәр номинациядә түбәндәге яшь категорияләре буенча кабул ителә:

- 1 нче төркем: 5 - 7 сыйныфлар
- 2 нче төркем: 8 - 9 сыйныфлар
- 3 нче төркем: 10 - 11 сыйныфлар.

4.5. Һәр катнашучыдан билгеләнгән үрнәк буенча персональ мәгълүматларны куллануга ризалык турында белешмә тапшыру таләп ителә (Кушымта 4 - Приложение).

4.6. Конференция кысаларында түбәндәге **4 номинация** буенча секцияләр эшләячәк:

**1. Журналистика. «Кызыл тышлы дәфтәрдән».**

1. ***«Хәтер», «Вветераннар – безнең горурлыгыбыз!»*** темасына хәзерге вакытта исән-сау булган сугыш һәм тыл ветераннары турында журналистик язмалар (репортаж, интервью, мәкалә, хат, һ.б.) кабул ителә. Иң яхшы язмалар Конференция материаллары җыентыгында урын алачак.

Журналистик язмаларның күләме Times New Roman, 14 кегель, 1,5 интервал белән 5-7 биттән артмаска тиеш.

2.**Балалар матбугаты бәйгесе.** ***«Тел.Милләт. Туфан», «Җиңү тәрәзәләре»*** темаларына багышланган мәктәп укучылары газеталары (журналлары) кабул ителә.

2.1.Бу бәйгедә катнашу өчен түбәндәге таләпләр һәм шартлар куела:

- газета 4 биттән ким булмаска тиеш;
- сәхифәләр (рубрика) төрлелеге, тема актуальлеге, дизайн-верстка үзенчәлеге хупланыла;
- газеталар **электрон һәм кәгазь вариантта** җибәрелә;
- редакция турында белешмә (редакция исемлеге, газетаның елы, күләме, форматы, чыгу ешлыгы һ.б.) һәм газетаның башка елларда чыккан берничә санын да җибәрү сорала;
- иң яхшы газета редакцияләре **Конференциягә чакырыла**. Җиңүчеләр республика балалар матбугаты белән танышачак.

**2. Драматургия. «Театр яктылыкка, нурга илтә!..» Сәхнәләштерү.**

***«75 ел... Җиңү белән!»***, **“*Сугыш чоры геройлары*”** темаларына поэзия, проза яки драматургия әсәрләреннән яки үзегез иҗат иткән әсәрдән бер өзекне сәхнәләштерү.

2.1.Бу бәйгедә катнашу өчен түбәндәге таләпләр һәм шартлар куела:

- вакыты – 15 минутка кадәр;
- сәхнәләштерелгән өзекнең видео вариантын җибәрү мәҗбүри!

2.2.Бәйгедә катнашу өчен сәхнәләштерелгән өзек белән видео вариант һәм гариза **драматургия** секциясе дип саклана һәм шул исем белән Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең электрон әрҗәсенә **kzlar_ile@mail.ru** адресына һәм почта аша CD яки DVD дискта гимназия адресына җибәрелә.

**3. Фәнни эшләр. “Үзем сайлаган язмыш”.**

*“Әдәбият-сәнгать кешенең җанын тәрбияли. Йөрәген уйларга өйрәтә. Кешене аның рухы кеше иткән...” (Туфан Миңнуллин)*

Конференциядә катнашучылардан “XX гасырның икенче яртысында татар драматургиясе. Туфан Габдулла улы Миңнуллин тууына 85 ел тулуга багышлана.” темасы буенча фәнни тикшеренүләр кабул ителә.

Конференциядә түбәндәге мәсьәләләр буенча фикер алышу күздә тотыла:

– XX гасырның 2 нче яртысы сәхнә әдәбиятында тема-мотивлар төрлелеге һәм аларның сәнгатьчә чагылышы;

– 1960-80 еллар татар драматургиясен әйдәп баручы әдипләр иҗатында яңарыш билгеләре (Х.Вахит, Ш.Хөсәенов, А.Гыйләҗев һ.б. буенча);

– Т.Миңнуллин иҗатында татар милли характеры һәм аның сәнгатьчә гәүдәләнеше;

– XX гасырның 2 нче яртысында балалар өчен язылган сәхнә әсәрләрендә үзенчәлекле образлар;

– Әлеге чор драма әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләре.

**Фикер алышу өчен тәкъдим ителгән темалар фәнни эш исеме итеп алынмый.**

3.1.Фәнни эшләрнең күләме Times New Roman, 14 кегель, 1,5 интервал белән 10 биттән артмаска тиеш. Фәнни җитәкчеләр саны **ике укытучыдан** артмаска тиеш.

3.2. Конференция эшләрен бәяләүгә таләпләр:

- билгеләнгән теманы яктырту;
- эшкә иҗади якын килү;
- фәнни-иҗади эшнең укучы яшенә туры килүе;
- заманча компьютер технологияләрен куллану;
- югары дәрәҗәдәге осталык, яңалык, кызыклы идеяләр һ.б.;
- башка конференциядә кулланылмавы.

3.3. **Фәнни-иҗади эшләр кәгазь вариантсыз каралмый!**

3.4. Бәйгедә катнашу өчен материаллар **фәнни-эш** дип саклана һәм шул исем белән Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең электрон әрҗәсенә **kzlar_ile@mail.ru** адресына һәм почта аша гимназия адресына җибәрелә.

**4. «Утырып уйлар уйладым».**
**Укытучылар һәм китапханәчеләр номинациясе**

4.1.**«Тәҗрибә» мастер-класс бәйгесе.**

«Тел, тел, тел дибез...» *(Т.Миңнуллин),*

«Тәрбия сәгате»**,** «Уен – чын шөгыльгә, тормыш көрәшенә һәм хезмәткә әзерләнү ул» (Н.Исәнбәт),

«Гаилә. Мәктәп. Шәхес» темаларына багышланган тәҗрибә уртаклашу

материалларына конспектлар кабул ителә.

1). Бу бәйгедә катнашу өчен түбәндәге таләпләр һәм шартлар куела:

-Документлар файллы папкада кабул ителә. 1нче бит – титул бите, катнашучының исем фамилиясе, әтисенең исеме, эшләгән урыны, вазыйфасы, мастер-классның исеме язылa, ә 2 нче биттә –гариза.

-Папкага мастер-классның конспекты куела. Иң яхшы конспектлар Конферения җыентыгында урын алачак.

- Вакыты – 10-15 минутка кадәр. Педагог мастер-класста катнашучылар санын үзе билгели һәм залдан сайлап ала. Әгәр таратма материал булса, жюри әгъзаларына күрсәтергә тиеш.;

2) Бу бәйге түбәндәге критерийлар нигезендә бәяләнә:

- сайланган теманы эчтәлеген киң һәм тирән чагылдыру, актуальлек;
- эчтәлегенең фәннилеге;
- һөнәри мастерлык;
- методик һәм практик әһәмияте;
-туган телне өйрәнүгә яңа заманча якын килү;
-туган телдә сөйләм культурасы;
-мастер-класс конспектының сыйфаты.

3) Бәйгедә катнашу өчен материаллар **мастер-класс** дип саклана һәм шул исем белән Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең электрон әрҗәсенә **kzlar_ile@mail.ru** адресына һәм почта аша гимназия адресына җибәрелә.

4.2. **«Сандыгымда – Туган тел музее» бәйгесе.**

Бу бәйгедә катнашу өчен түбәндәге таләпләр һәм шартлар куела:

- Милли сандыкта Туган тел музее булдыру.

- Сандыктагы музей ядкярләре (экспонатлары) турында видеохәбәр әзерләү. Регламенты -1-3 минут.

- Видеохәбәрне «Сандык – музей»**,** Ф.И.О., мәктәп исеме белән сакларга һәм шул исем белән Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең электрон әрҗәсенә **kzlar_ile@mail.ru** адресына юлларга.

- Иң яхшы сандыктагы музейлар Конференция күргәзмәсенә куела һәм чарадан соң авторларга кайтарыла.

## 5. Конференцияне үткәрү вакыты

5.1. Конференциядә катнашу өчен гаризалар һәм эшләр **2020 елның 13 гыйнварыннан 2020 елның 17 февралена** кадәр кабул ителә.

5.2. Конференция номинацияләрендә катнашучылар фәнни һәм иҗади эшләрен тиешле гариза (Кушымта 1-3), CD яки DVD диск һәм **секция исеме** белән белән Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең электрон әрҗәсенә **kzlar_ile@mail.ru** һәм почта буенча: **420034, ТР, Казан шәһәре, Мәскәү районы, Декабристлар урамы, 89А** адресына эшләрнең **кәгазь вариантын** китерә.

5.3. Конференциянең барлык номинацияләре дә: журналистика, фәнни эшләр, драматургия, китапнамә 2 этапта үтә.

5.4. **1 этап** – сайлап алу этабында жюри Конференциягә җибәрелгән фәнни һәм иҗади эшләрне карый һәм иң яхшыларын секцияләрдә чыгыш ясау өчен тәкъдим итә.

5.5. **Жюри эше (2020 елның 19 февраленнан – 2020 елның 2 мартына кадәр):**

- Жюри Конференция номинантларын һәм лауреатларын билгели;
- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Оештыру комитеты, Конференция дипломантларына Конференциядә катнашу өчен, чакыру хаты җибәрә.

5.6. Оештыру комитеты Конференция рекламасын Татарстан Республикасы мәгълүмат чараларына, интернет порталларына бирергә хокуклы.

### 6. **Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү**

6.1. Драматургия, журналистика, фәнни эшләр язу, укытучылар һәм китапханәчеләр секцияләр буенча Конференция нәтиҗәләре 2020 елның **9 мартында** билгеле була. Конференция секцияләрендә чыгыш ясаучы укучылар, укытучылар һәм китапханәчеләр исемлеге Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең сайтында **9 мартта** урнаштырыла.

6.2. Драматургия, журналистика, фәнни эшләр язу, укытучылар һәм китапханәчеләр секцияләрнең эше **2020 елның 21 мартында** Ф.Г.Аитова исемендәге 12 нче гимназиядә (Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 89 А) уза.

6.3. Конференция аерым номинацияләрдә һәр яшь төркеме буенча иң яхшы фәнни һәм иҗади эш авторларын дипломнар белән билгели (җиңүче, призёр, лауреат). Катнашучыларга шаһәдәтнамәләр электрон формада җибәрелә.

### 7. Өстәмә мәгълүмат

Элемтә өчен:
8927-430-81-05 Вәлиева Мәйсәрә Насртдин кызы
8917-915-57-88 Газизуллина Рәмилә Гамил кызы
e-mail: kzlar_ile@mail.ru

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
VII республика конференциясе Нигезләмәсенә
**Кушымта 1**

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның VII республика конференциясенең
**«Драматургия. Сәхнәләштерү» номинациясендә** катнашу өчен
**Гариза**

<table>
<tr><th rowspan="2">Белем бирү оешма-сының тулы исеме</th><th rowspan="2">Әсәрнең исеме, авторы</th><th colspan="3">Катнашучылар исемлеге</th><th rowspan="2">Җитәкче-нең Ф.И.О; телефоны, электрон адресы</th><th rowspan="2">Декорация, музыкаль бизәлеш турында мәгълүмат</th></tr>
<tr><th>Ф.И.О.</th><th>Уйнаган роле</th><th>Туган вакыты, тулы яше, сыйныфы</th></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

Сәхнәләштерелгән өзеккә бәяләмә (аннотация)

«_____ » _____________ 20__ ел.

***Искәрмә:*** *Гаризалар тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.*

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
VII республика конференциясе Нигезләмәсенә
**Кушымта 2**

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның VII республика конференциясендә катнашу өчен
**Гариза**

| № | Ф.И.О., сыйныфы | Автор укыган белем бирү оешмасының Устав буенча тулы исеме | Фәнни яки иҗади номинациясе, эшнең исеме, күләме | Секция | Җитәкченең Ф.И.О.; предметы, телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Фәнни яки иҗади эшкә бәяләмә (аннотация)

«____» ___________ 20__ ел.

*Искәрмә: Гаризалар тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.*

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
VII республика конференциясе Нигезләмәсенә
**Кушымта 3**

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның VII республика конференциясенең
**«Утырып уйлар уйладым»** номинациясендә
**(укытучылар һәм китапханәчеләр секциясе)**
катнашу өчен
**Гариза**

| №<br>№ | Ф.И.О., автор(лар)ның вазыйфасы, электрон адресы, телефоны | Автор(лар)ның Устав буенча эш урыны | Мастер-классның яки “Сандык – музей” видеохәбәрнең исеме | Оешма директорының Ф.И.О.; телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Фәнни-иҗади эшкә бәяләмә (аннотация)

«_____»  __________ 20___ ел.

*Искәрмә: Гаризалар тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.*

**Кушымта 4 - Приложение**

**Согласие на обработку персональных данных**

**Я, ___________________________________________________________________,**

*(ФИО родителя или законного представителя)*

паспорт _____ ____________, выдан________________________________________________

*(серия, номер)* *(когда, кем)*

_______________ ________________________________________________________________

*(в случае опекунства / попечительства указать реквизиты документа, на основании которого осуществляется опека или попечительство)*

__________________________________________________________________________________

*(адрес)*

даю согласие на обработку персональных данных моего ребенка

__________________________________________________________________________________

*(фамилия, имя, отчество ребенка)*

паспорт _____ _____________, выдан ___________________________________________________

*(серия, номер)* *(когда, кем)*

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

*(адрес)*

оператору Министерства образования и науки Республики Татарстан для участия в конференции.

Перечень персональных данных, на обработку которых дается согласие: фамилия, имя, отчество, школа, класс, домашний адрес, дата рождения, телефон, адрес электронной почты, результаты участия в заключительном этапе конференции.

Оператор имеет право на сбор, систематизацию, накопление, хранение, уточнение, использование, передачу персональных данных третьим лицам - образовательным организациям, органам управления образованием районов (городов), Министерству образования и науки РТ, Министерству образования РФ, иным юридическим и физическим лицам, отвечающим за организацию и проведение различных этапов конференции, обезличивание, блокирование, уничтожение персональных данных.

Данным заявлением разрешаю считать общедоступными, в том числе выставлять в сети Интернет, следующие персональные данные моего ребенка: фамилия, имя, класс, школа, результат заключительного этапа конференции, а также публикацию в открытом доступе сканированной копии работы.

Обработка персональных данных осуществляется в соответствии с нормами Федерального закона Российской Федерации от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных».

Данное Согласие вступает в силу со дня его подписания и действует в течение 3-х лет.

______________________ ______________________

(личная подпись) (дата)